ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК РЕСУРСЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**Приказ** **Боерык**

08.06.2026 ел Казан № 232-тэ

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында биләве коррупция куркынычы белән бәйле, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 2-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

**боерам:**

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында биләве коррупция куркынычы белән бәйле, аларны биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында» Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018

елның 2-од номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 22.05.2020 № 148-од, 26.01.2022 № 18-од боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында аларны билгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау хакында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Кушымтада бирелә торган «Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында (алга таба – Комитет) аларны билгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.»;

5 пунктның 5.1 пунктчасын үз көчен югалткан дип танырга;

6 пунктта «Ю.Б. Матвеевка» сүзләрен «Р.М. Мутахаровка» сүзләренә алмаштырырга;

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында биләве коррупция куркынычы белән бәйле, аларны билгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында һәм хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиеш булган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлегендә:

«Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетында аларны билгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырырга тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге».

Рәис Ф.С. Батков